**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«04» 02 2021 ел    Яр Чаллы    № 287

Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең 2009 елның 6 апрелендәге 90 номерлы «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча комиссия төзү турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы хөкүмәте комиссиясе турында» 2006 елның 30 октябрендәге 529 номерлы Карарын үтәү йөзеннән, шулай ук Россия Федерациясе транспорт министрының 1997 елның 8 январендагы 12 номерлы боерыгы белән расланган «Автобусларда пассажирлар йөртү иминлеген тәэмин итү турында нигезләмә»гә таянып, Тукай муниципаль районы территориясендә юлларның торышын тикшерү һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

**КАРАР БИРӘ:**

1. Башкарма комитет Җитәкчесенең 2009 елның 6 апрелендәге 90 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм юлларны тикшерү комиссиясе составыннан чыгарырга:

- А.С. Ибраһимовны;
- Т.Н. Мирзаеваны.

1.2. Юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм юлларны тикшерү комиссиясе составына кертергә:

- Сабиров Әлфәт Зыятдин улын – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
- Миниханов Рөстәм Рафис улын – суд приставлары хезмәтенең Тукай районы бүлеге башлыгы.

2. Тукай муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм юлларның торышын тикшерү комиссиясе составын кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны муниципаль районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе    А.Р. Хәбибуллин

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 04.02.22 284 номерлы карарына кушымта

Тукай муниципаль районы территориясендә юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм юлларның торышын тикшерү комиссиясе составы

**Рәис:**
Хәбибуллин А.Р. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе.

**Комиссия секретаре:**
Мадярова Д.Ә. – Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге баш белгече.

**Комиссия әгъзалары:**

1. Елисеев В.А. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге башлыгы, полиция полковнигы – комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча);
2. Ганиев Ш.М. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенең юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе бүлеге башлыгы (килешү буенча);
3. Вильданов Р.Р. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлегенең юл хәрәкәте иминлеге буенча дәүләт инспекциясе бүлеге өлкән дәүләт инспекторы (килешү буенча);
4. Шаябтдинов А.А. – Россия Эчке эшләр министрлыгының Тукай районы буенча бүлеге участок вәкаләтлеләре бүлеге башлыгы (килешү буенча);
5. Алгуатов К.Р. – ЮХИДИ юл патруле хезмәте махсус батальоны 2 рота командиры урынбасары (килешү буенча);
6. Сабиров Ә.З. – «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы;
7. ЗагретдиновФ.С. – Тукай муниципаль районы финанс-бюджет палатасы рәисе;
8. Гәрәев И.Р. – Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге башлыгы (килешү буенча);
9. Сәхбиев М.Ш. – Биклән авыл җирлеге Башлыгы (килешү буенча);
10. Төхбәтуллин Р.Г. – Тукай муниципаль районы «Пассажирлар йөртүчеләр берлеге ассоциациясе» башкарма директоры (килешү буенча);
11. Сабирҗанов Г.Г. – «Тукай районы үзәк хастаханәсе» баш табибы (килешү буенча);
12. Насыйров А.Х. – Татарстан Республикасы гадәттән тыш хәлләр министрлыгының гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру бүлеге әйдәп баручы белгече (килешү буенча);
13. Миниханов Р.Р. – суд приставлары хезмәтенең Тукай районы бүлеге башлыгы (килешү буенча);

14. Карпов С.И. – «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУнең Яр Чаллы шәһәрендәге территориаль идарәсе башлыгы (килешү буенча);

15. Гыйльметдинова Р.Р. – «Юл хәрәкәте иминлеге» ДБУнең Яр Чаллы шәһәрендәге территориаль идарәсе профилактика бүлеге башлыгы (килешү буенча);

16. Хөсәинов Р.Ә. – «Татавтодор» АҖ Түбән Кама филиалы директоры (килешү буенча);

17. Гайбадуллин Р.Н. – «Главтатдортранс» ДКУ әйдәп баручы белгече (килешү буенча);

18. Лобин С.П. – «Волговятскуправдор» ФКУнең Яр Чаллы шәһәрендәге филиалы директор (килешү буенча);

19. Жаренков А.Г. – ТР буенча Дәүләт автоюл күзәтчелеге идарәсе башлыгы (килешү буенча);

20. Зәкиев Р.М. – «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы җитәкчесе - «Якты юл» гасетасы баш мөхәррире (килешү буенча).